РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«28 » 09 2023 г. №1495

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 18 июнендәге 418 номерлы карары белән расланган, Муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза ясау турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 18 июнендәге 418 номерлы карары белән расланган, Муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза ясау турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Нигезләмә эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен артык вазыйфалар, тыюлар һәм чикләүләр кертә торган яисә аларны кертүгә этәрә торган актлар проектында эшкуарлык яисә җирле

бюджетларның нигезләнмәгән чыгымнары барлыкка килүгә китерә торган нигезләмәләрне ачыклау максатларында, муниципаль норматив хокукый актлар проектларының (алга таба - актлар проектлары) җайга салу йогынтысын бәяләүне үткәрү тәртибен, шулай ук эшкуарлык яисә башка икътисадый эшчәнлек субъектларының һәм җирле бюджетларның нигезләнгән чыгымнарын барлыкка китерүче нигезләмәләрне ачыклау максатларында муниципаль норматив хокукый актларга (алга таба норматив хокукый актлар) экспертиза ясау тәртибен билгели.

Муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектлары өчен кирәгеннән артык мәҗбүри таләпләр кертә торган нигезләмәләрне, инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен бурычлар яисә аларны кертүгә этәрә торган йөкләмәләрне, шулай ук эшкуарлык һәм башка икътисадый эшчәнлек субъектларының һәм җирле бюджетларның нигезләнмәгән чыгымнары барлыкка килүгә китерә торган нигезләмәләрне ачыклау максатларында уздырыла.

Җайга салу йогынтысын бәяләү өлкәсендә вәкаләтле бүлекчә булып Ютазы муниципаль районы башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге (алга таба - вәкаләтле бүлек) тора. Вәкаләтле бүлекчә актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне үткәрүне һәм норматив хокукый актларга экспертиза уздыруны норматив һәм методик яктан тәэмин итә.

Эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү һәм норматив хокукый актларга экспертиза ясау җирле үзидарә органнары тарафыннан «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 131-ФЗ номерлы Федераль закон), «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайлау йогынтысын бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза үткәрү тәртибе турында " 2014 елның 7 мартындагы 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 10 маендагы 30-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан әлеге нигезләмә һәм башка норматив хокукый актлар белән кабул ителә (чыгарыла) торган Татарстан Республикасында гамәлдәге норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын ачык бәяләү тәртибен раслау турында" 2012 елның 31 декабрендәге 1182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары, әлеге нигезләмә һәм башка норматив хокуый актлар  нигезендә уздырыла.».

1.2. Нигезләмәнең 2 пункты 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) җирле салымнарны һәм җыемнарны билгеләүче, үзгәртүче, туктатып торучы, юкка чыгаручы муниципаль берәмлекләр вәкиллекле органнарының норматив хокукый актлары проектларына;»;

1.3. Нигезләмәнең 4 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга  һәм http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы составында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина